**УКАЗ**
**ПРЕЗИДЕНТА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ПРЕЗИДЕНТЫ**
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында**

Татарстан Республикасында эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил институты формалаштыру максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил вазыйфасын гамәлгә куярга.

2. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил вазыйфага Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә.

3. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил түбәндәге вәкаләтләрне тормышка ашыра:

Татарстан Республикасында эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының (алга таба – гариза бирүчеләрнең) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының, аларның вазыйфаи затларының карарларына һәм (яисә) гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләрен карый, гариза бирүчеләрне (әгәр дә гариза бирүче оешма булса, аларның вәкилләрен) шәхсән кабул итә;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органына, җирле үзидарә органына, аларның вазыйфаи затларына, ул үзе аларның карарларында һәм (яисә) гамәлләрендә (гамәл кылмауларында) гариза бирүченең хокуклары бозылуны һәм законлы мәнфәгатьләре бозылуны ачыкласа, күрсәтелгән хокукларны һәм законлы мәнфәгатьләрне торгызуның мөмкин булган һәм зарури чараларына карата тәкъдимнәре булган бәяләмәсен җибәрә;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы җитәкчесенә гариза бирүченең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуларны бетерү һәм (яисә) гариза бирүченең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга юл куйган вазыйфаи затларына дисциплинар җәза куллану буенча чара күрү турында мөрәҗәгать итә;

дәүләт хакимиятенең компетентлы органнарына, әгәр алар, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил фикере буенча, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органының вазыйфаи заты, җирле үзидарә органының вазыйфаи заты карарларында һәм (яисә) гамәлләрендә (гамәл кылмауларында) административ хокук бозу яисә җинаять составы билгеләре булу турында таныкласа, шикаятьне тикшерү барышында алынган материалларны җибәрә;

дәүләт хакимиятенең компетентлы органнарына, әгәр алар, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил фикере буенча, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органының, җирле үзидарә органының һәм аларның вазыйфаи затларының карарларында һәм (яисә) гамәлләрендә (гамәл кылмауларында) күрсәтелгән компетентлы оранпар тарафыннан аларның вәкаләтләре нигезендә чара күрү өчен нигез булуы турында таныкласа, шикаятьне тикшерү барышында алынган материалларны җибәрә.

4. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестры турында» 2006 елның 18 гыйнварындагы ПУ-9 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 12 мартындагы ПУ-121 номерлы, 2010 елның 1 апрелендәге ПУ-183 номерлы, 2010 елның 10 июнендәге ПУ-378 номерлы, 2010 елның 30 июнендәге ПУ-416 номерлы, 2010 елның 3 августындагы ПУ-512 номерлы, 2010 елның 2 сентябрендәге ПУ-585 номерлы, 2011 елның 31 гыйнварындагы ПУ-34 номерлы, 2011 елның 20 июлендәге ПУ-360 номерлы, 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-620 номерлы, 2011 елның 13 октябрендәге ПУ-646 номерлы, 2011 елның 30 ноябрендәге ПУ-774 номерлы, 2012 елның 20 февралендәге ПУ-126 номерлы, 2012 елның 24 маендагы ПУ-375 номерлы, 2012 елның 13 августындагы ПУ-649 номерлы, 2012 елның 20 августындагы ПУ-681 номерлы, 2012 елның 19 октябрендәге ПУ-880 номерлы һәм 2013 елның 18 гыйнварындагы ПУ-31 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестрының 1 өлешендәге 1 бүлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| « | Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советында вәкаләтле вәкиле** | 01-1-1-03 | » |

позициясеннән соң түбәндәге эчтәлекле позиция өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| « | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил | 01-1-1-03[1] | ». |

5. Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенә ун көн вакыт эчендә Татарстан Республикасы Президенты актларын әлеге Указга туры китерү буенча тәкъдимнәр кертергә.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына «Россия Федерациясендә эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилләр турында» федераль законның үз көченә керүе көненнән утыз көн вакыт эчендә Татарстан Республикасында Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында Татарстан Республикасы законы проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертергә.

7. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2013 ел, 24 гыйнвар
№ ПУ-44